№3, Гыйнвар 2025

# Чишмә башы

МБГБУ "Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе"

**Бу санда:**


- *2025 нче ел – Ватанны саклаучылар елы*
- *Ай вакыйгалары*
- *Балалар иҗаты*
- *25 нче гыйнвар – Студентлар көне*
- *27 нче гыйнвар – Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итү көне*
- *Ял сәгатьләрендә*




## <u>Ак кыш</u>

Яратам мин ап-ак төсне,
Бөтен дөнья ап-ак төсле.
Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.
Шундый якты, шундый нурлы,
Бөтен дөнья ак кына…
Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына.

(Роберт Миңнуллин)

# 2025 нче ел – Ватанны саклаучылар елы



«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз.

2025 елда бөтен илебез белән совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 80 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Бу Җиңү – безнең иң зур горурлыгыбыз. Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтү кысаларында, безнең алда торган бурычларның әһәмиятен исәпкә алып, илебездә һәм республикада 2025 ел – Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде.

Безнең авыл җирлегендә дә батыр, үз иленең патриоты булган егетләребез бар. Балаларыбызның күбесенең абыйлары, туганнары үзләренең хәрби бурычларын үти. Алар бүген дә ерак Украина җирендә. Сарай-Чокырча авылы егете капитан Айрат Галәветдинов Лиман өчен барган сугышта һәлак булды. Мәктәбебездә аның истәлегенә хәтер тактасы куелды, Юнармия отрядына геройның исеме бирелде.

Укучылар музей җитәкчесе белән берлектә егетләребез турында мәгълүматлар туплый, әти-әниләре белән элемтәдә тора, аларга хатлар язалар. Әлеге хатларның үзебезнең үк авылдашларга барып ирешүе искиткеч зур сөенеч.

Үткәненә хөрмәт сакламаганның – киләчәге юк. Халкыбызның данлы үткәне турындагы истәлекләрне кадерләп саклап, буыннан-буынга тапшыра килү, шулар үрнәгендә илебезнең хөрмәткә лаеклы гражданнарын тәрбияләү – безнең изге бурычыбыз.

## Ай вакыйгалары



Безнең мәктәп укучылары Андреев Марат, Таһирова Ясминә, Гыйльметдинов Заһир һәм Миңнуллин Илмир инглиз теле буенча «Who is the best» команда уенында катнаштылар һәм 2 нче урынны алдылар. Катнашучылар бик яхшы белемгә ия булуларын һәм команда рухын күрсәттеләр. Укучыларны котлыйбыз һәм алга таба уңышлар телибез!

Украинада махсус хәрби операция барышында батырларча һәлак булган офицер Галәветдинов Айрат Әхәт улы – мәктәбебез горурлыгы. 12 нче гыйнвар көнне Айратны тәрбияләп үстергән гаилә турында тапшыру төшерү өчен ТНВ каналы килде. Музейда Айрат Әхәт улына багышланган бүлектә әти-әнисе һәм укытучылар истәлекләр белән уртаклаштылар.





18 нче гыйнвар көнне Арча шәһәре стадионында районыбызның белем бирү учреждениеләре укучылары, студентлары арасында чаңгы ярышы булып узды. 2013-2014 нче елгы кызлар арасында Минһаҗева Зәлия, 2011-2012 нче елгы кызлар арасында Гатауллина Ризәлә 2 нче урынны алды. Нәтиҗәдә, төп гомуми белем мәктәпләре арасында Урта Курса мәктәбе 2 нче урынны яулады. Афәрин!

18 нче гыйнвар көнне мәктәбебездә Зәйнетдинов Алмаз истәлегенә волейбол турниры үткәрелде. Барлыгы 6 команда көч сынашты. Бөтен команда да бик көчле уен күрсәттеләр. Турнир нәтиҗәләре буенча 1 урында Сарай-Чокырча авылы, 2 урында Курса һәм 3 нче урында Арча командалары. Һәр командага истәлекле бүләкләр тапшырылды.



**Ватанны саклаучылар елы.**

80 ел элек совет гаскәрләре кешеләрне фашистлардан азат итә. Сугыш китергән югалтулар һәм газаплар һәр йөрәктә тирән эз калдырды. Без куркыныч һәм кырыс сугышка каршы! Үзләрен җәлләмичә өлеш керткән барлык солдатларны онытырга хакыбыз юк!

Совет солдатының батырлыгы чын патриотизм символы булып тора. Чөнки алар үз Ватаннарының якты киләчәген саклаганнар. Батырларның куркусыз булулары аркасында без матур тормышта яшибез. Туган җиребездә һәрчак тынычлык һәм иминлек хөкем сөрсен иде.

***Гафуров Рәсим***
*7нче сыйныф укучысы*

**Югалтулар белән килгән Җиңү!**

1941нче елның 22нче июнь таңы... Сәгать иртәнге 4... Илебез халкы авыр эш атнасыннан соң тирән йокыда. Беркем дә, хәтта саташулы төшендә дә, бер җирдән дә явызлык көтми. Ләкин нәкъ менә шушы минутларда фашист илбасарлары үзләренең меңләгән туплары һәм очкычлары белән безнең чик буе заставаларын, хәрби казармаларын, элемтә үзәкләрен тупка тоталар. Шул ук минутта дошман бомбардировщиклары да һавага күтәрелеп, тыныч илебез өстенә меңәрләгән бомбаларын ташлыйлар.

Сабан туена дип хәзерләнгән тастымалларга батырлар биленең ныклыгын сынарга насыйп булмый. Чиккән кулъяулыклар кыңгыраулы дугаларга, ат башларынна бәйләнми кала – барысына да сугыш төтене куна, күз яше сеңә. 1418 көнгә сузылган канкойгыч сугыш шулай башланып китә. Бу 1418 утлы көн һәм төн халкыбыз җилкәсенә күтәрә алмаслык йөк булып ята. Сугышның иң беренче көннәреннән үк Татарстан ир-егетләре, кызлары илне саклаучылар сафына баса. Яу кырына республикабызның 560 меңнән артык кешесе чыгып китә, 350 меңнән артыгы әйләнеп кайта алмый...

Быел Бөек Җиңүгә 80 ел булачак. Никадәр көч, югалтулар белән килгән аяз күк йөзенең тынычлыган саклый алсак иде.

***Бикбаева Руфинә***
*7нче сыйныф укучысы*

**Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел!**

1941 елның июнендә, Гитлер Алманиясе хыянәтчел рәвештә Советлар Союзына һөҗүм иткәч, дөнья мәңгегә караңгылык упкынына чумган кебек була. Сугыш шәһәрләрне һәм авылларны камап ала, гаиләләрне һәм тыныч көннәрне җимерә. Үз гомерләрен Ватан өчен бирергә әзер булган бик күп кешеләр үз теләкләре белән фронтка китә. Болар - Армия солдатлары гына түгел, шәфкать туташлары да, Гражданнар оборонасы буенча белгечләр,

**Бөек Җиңүгә 80 ел!**

Ел саен 9 майда без Җиңү көнен билгеләп үтәбез, безнең азатлык хакына үз гомерләрен биргәннәрне искә алабыз.

Быел Бөек Ватан сугышының соңгы залплары яңгыраганга 80 ел булачак. Шушы 80 ел эчендә дөнья танымаслык булып үзгәрде. Технологияләр алга китте, яңа мөмкинлекләр тәэсирендә фән һәм сәнгать үсте. Болар барысы да 1945 елның маенда яулап алынган тынычлык аркасында булды.

Һәйкәлләр һәм мемориаллар, китап һәм фильмнар, чаралар һәм мәктәп дәресләре – болар барысы да вакытларның тере бәйләнешен сакларга ярдәм итәләр. Без Бөек Ватан сугышы турындагы истәлекләрне сакларга һәм һәр адым геройларның лаеклы мирасы булсын дип эшләргә тиеш. Хәтерләүчеләр булганда, аларның батырлыклары мәңге яшәячәк.

***Гатауллина Ризәлә***
*7нче сыйныф укучысы*

**Сугыш афәте булмасын!**

1941 нче елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергән. Ул вакытта Ватанны сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелгән. Безнең буынны саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас!

Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Яшь-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау өчен фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип бар тырышлыкларын куялар.

Хәзерге вакытта кайбер балалар сугыш афәтләрен белмичә иркә булып яшиләр. Әйдәгез, ветераннарны кадерләп яшик!

***Бикбаев Ильяс***
*7нче сыйныф укучысы*

инженерлар һәм башка бик күпләр була.

Һәркем җиңүне мөмкин кадәр якынайтырга тырыша. Ул сугышның күләгәләре әле дә безнең йөрәкләрне яндыра, күп санлы буыннар язмышына тирән эз сала. Бөек Ватан сугышы вакытында барлык милләтләрнең дус-тату булуы, батырлыгы, фронтта да, тылда да һәркемнең тырышлыгы фашистларны җиңәргә ярдәм итә.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы кешелек тарихында, бигрәк тә илебез тарихында мөһим чара булып тора. Бу вакыйга безгә җиребездә азатлык һәм тынычлык яулау өчен үткән авыр сынауларны искә төшерергә ярдәм итә.

***Миннеханова Гөлчәчәк***
*8нче сыйныф укучысы*

# 25 нче гыйнвар – Студентлар көне

25 нче гыйнвар көнендә Россиядә студентлар көне билгеләп үтелә. 1755 елның 25 гыйнварында (иске стиль буенча 12 гыйнварда) Россия императрицасы Елизавета Петровна, Петр 1 кызы, Мәскәү университеты ачылу турында указга кул куя. Ул Россиядә беренче шундый уку йорты була. 2007 елда президент В.В. Путин федераль законга кул куйды.

Студентлар көне алдыннан безнең мәктәпне тәмамлаган студентлардан интервью алдык.



**Миннеханова Чулпан Гаделҗан кызы**
*Социаль һәм гуманитар белем институты*
*3нче курс студенты*

1. **Сүзне дәвам ит: "Студент - ул..."**

Студент – ул беркайчан да йокысы туймаган һәм гел ашыйсы килгән кеше.

2. **Укуда яхшы нәтиҗәләргә ничек ирешәсез?**

Укуда яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен, тырышып укырга, үзеңне яхшы яктан гына күрсәтергә кирәк.

3. **Сезнең студент тормышында булган иң истә калган мизгел?**


Студент булу – ул иң кызык чак. Иң истә калганы «Студент көне» бәйрәме.

4. **Мәктәпне сагынасызмы?**

Әлбәттә, сагынабыз, дәресләрдә утыру, укытучылар гел истә.

5. **Чыгарылыш класс укучыларына нинди киңәш бирер идегез?**

Чыгарылыш класс укучыларына, киңәшем: ОГЭга әйбәтләп әзерләнергә, яхшы билгеләргә бирергә, уку көллиятен сайлаганда, уйлап, үзләре теләгән уку йортына керсеннәр, соңыннан үкенерлек булмасын.



**Гарифуллин Галим Гадел улы**
*Габдулла Тукай исемендәге*
*Арча педагогика көллияте*
*2нче курс студенты*

1. **Сүзне дәвам ит: "Студент - ул..."**

Студент ул – һәрчак йокысы туймаудан интегүче, һәрвакыт ач, башын бәрә-бәрә укып, шәхси тормышына һич вакыты калмаучы кешесыман бер зат. Әлбәттә, бу шаяру гына, әмма, дусларым, һәр шаярудa дөреслек өлеше дә бар, диләр бит. Чыннан да, студент булгансың икән, вакытыңны бушка әрәм итмичә, кайвакыт хәтта йокламыйча да гыйлем алырга әзер бул!

2. **Укуда яхшы нәтиҗәләргә ничек ирешәсез?**

Укуда яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен бер генә дәресне дә калдырмыйча укырга йөрергә кирәк, үзем өчен, алдагы тормышым өчен кирәк дип, тырышырга кирәк.

3. **Сезнең студент тормышында булган иң истә калган мизгел?**

Беренче курста физика фәненнән имтиханда автомат “биш” ле алган мизгел.

4. **Мәктәпне сагынасызмы?**

Сагынам, әмма сагышланмыйм.

5. **Чыгарылыш класс укучыларына нинди киңәш бирер идегез?**

Әгәр укуны сөймәсәгез, авыр булачак, укырга, белем алырга яраткан кеше генә студент тормышының авырлыгын җиңә ала, минемчә. Шуңа күрә үзегездә үзегез укуга мәхәббәт тәрбияләгез.



**Мингазов Самат Марат улы**
*И.В. Әухәдиев исемендәге*
*Казан музыка көллияте*
*2нче курс студенты*

1. **Сүзне дәвам ит: "Студент - ул..."**

Студент – урта һәм югары уку йортында укучы.

2. **Укуда яхшы нәтиҗәләргә ничек ирешәсез?**

Мин биредәге кагыйдәрне үтим: вакытында ятам һәм даими рәвештә ял итәм; уку көнен планлаштырам һәм приоритетларны билгеләп куям; уңышлы студентлар интернет чыганакларындагы өстәмә мәгълүмат белән кызыксынып, укыту программасы белән генә чикләнмиләр; хаталар өстендә эшлим; дәресләргә соңга калмыйм.

3. **Сезнең студент тормышында булган иң истә калган мизгел?**

Истә калган мизгелләр күп инде. Шуларның берсе- беренче курс студентларына багышланган бәйрәм. Башта концерт булды, һәр бүлек студентларыннан бер номер кирәк иде. Кичен югары курс студентлары квест оештырдылар.

4. **Мәктәпне сагынасызмы?**

Әйе, сагынам.

5. **Чыгарылыш класс укучыларына нинди киңәш бирер идегез?**

Үзегезгә ышаныгыз. ОГЭ куркыныч түгел. Иң мөһиме, вакыт барында бар көчегезне куеп әзерләнегез, ахырдан терсәкне тешләрлек булмасын. Эшне соңгы көнгә калдырмагыз. Имтихан алдыннан башны ял иттерү яхшы булачак.



**Гайнуллина Зөләйха Булат кызы**
*Казан дәүләт медицина университеты-ның медицина-фармацевтика көллияте*
*1нче курс студенты*

1. **Сүзне дәвам ит: "Студент - ул..."**

Актив тормыш алып баручы, яшьлек дәртен саклаучы, күңел ача белүче, киләчәккә зур хыяллар, планнар белән янып яшәүче һәм тирәнтен белем алырга омтылучы кеше.

2. **Укуда яхшы нәтиҗәләргә ничек ирешәсез?**

Мин бик тырышып белем алам, үз алдыма максатлар куям һәм аларга ирешергә омтылам.

3. **Сезнең студент тормышында булган иң истә калган мизгел?**

Минем өчен студент тормышында һәрбер мизгел кадерле. Күңелле мизгелләр еш була. Уку бик авыр булса да, кызыклы. Парларда кызыклы тәҗрибәләр үткәрәбез, төрле чараларда группадашлар белән актив катнашабыз.

4. **Мәктәпне сагынасызмы?**

Әйе, мәктәптә булган һәрбер мизгел күңелдә матур хатирә булып саклана.

5. **Чыгарылыш класс укучыларына нинди киңәш бирер идегез?**

Имтиханнарга әйбәтләп әзерләнергә, тырышырга киңәш итәм.

# 27 нче гыйнвар – Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итү көне

1944 нче елның 27 нче гыйнвары – Ленинградның камалыштан чыккан көне. Ленинград 1941нче елның 8нче сентябреннән 1944нче елның 27нче гыйнварына кадәр, 872 көнгә камалышта кала. Анда яшәүчеләр өчен бу үлем исе аңкып торган иң авыр көннәр була.

Камалышның беренче көннәреннән үк фашистлар шәһәрне вәхшиләрчә бомбага тота башлыйлар. Иң кыены – кешеләрне азык-төлек белән тәэмин итү. Булган запас тиз арада юкка чыга. 1941нче елның 25 нче декабреннән Ленинградта яшәүчеләр: эшләүчеләр – 350 г., хезмәткәр, балалар һәм кеше тәрбиясендә булучылар 200 г. ипи ала башлыйлар. Ашау нормасы биш тапкыр кимetelә. Кайгы һәр гаиләгә килә. Күп гаиләләр тулысы белән үлеп бетәләр. Әмма бу ленинградлыларны тез чүктерә алмый.

Без әлеге истәлекле көнне ел саен укучылар, укытучылар белән билгеләп үтәбез. Без Ленинград камалышы, ул чактагы йончыткыч көннәр, барлык авырлыкларга түзеп, үлемне җиңгән кешеләр турында сөйләшәбез. Һәр кеше боларның барысын да истә тотарга һәм үз Ватаныбызны яратырга тиеш!





## “Блокада икмәге” хәтер акциясе

27 гыйнвар – Бөек Ватан сугышы тарихында зур әһәмияткә ия булган көн. 1944 елның нәкъ шушы көнендә Ленинград блокадасы өзелеп, каһарман шәһәр фашист камавыннан азат ителә. Бу истәлекле датага багышлап, “Блокада икмәге” дип исемләнгән Бөтенроссия акциясе үтә. Әлеге акциягә Урта Курса төп гомумбелем мәктәбенең капитан Айрат Галяутдинов исемендәге яшьармиячеләре һәм "Җиңү волонтерлары" хәрәкәте әгъзалары да кушылды. Алар 6 нчы сыйныфта "Блокадалы Ленинград битләре» дигән мәгълүмат сәгате уздырдылар

Чарада катнашучыларга дошман камавында калган Ленинградта икмәк алырга хокук биргән карточкалар, икмәкне нәрсәдән пешергәннәре турында мәгълүматлар бирелде.

Әлеге акция илебез тарихында аеруча тирән фаҗигале эз калдырган Бөек Ватан сугышы турындагы тарихи хакыйкать үсеп килүче буын вәкилләре күңеленә бар дөреслектә барып җитсен, ата - бабаларыбыз каһарманлыгы киләсе буыннар хәтерендә дә саклансын өчен оештырыла.



Күтәрелде халык көрәшкә,
Күтәрелде яуга кешеләр:
Очучылар, иген игүчеләр,
Йортлар төзүчеләр,
эшчеләр.



## Икмәк турында мәкальләр һәм әйтемнәр

- ✓ *Ипи-тоз – якты йөз*
- ✓ *Ипи белән тоз - дару.*
- ✓ *Ярты телем ипи бөтен дөньяга җиткән.*
- ✓ *Эшләп ашасаң, арыш икмәге дә тәмле.*
- ✓ *Кышкы кар – көзге икмәк.*
- ✓ *Икмәк – илебезнең төп байлыгы.*
- ✓ *Ил терәге – икмәк.*
- ✓ *Икмәкнең валчыгы да изге һәм кадерле.*
- ✓ *Икмәк булса җыр да була.*
- ✓ *Икмәкне кадерләп, саклап тоту - ул барыбызның да изге бурычы.*




## “Тормыш юлы”

Илебез халыкның тормыш шартларын уңайландыру өчен төрле чаралар үткәреп карый.

1941 елның ноябре ахырында Ладога күле өстеннән автомобиль юлы салынган. Халык аны “Тормыш юлы” дип атый. Боз өсте буйлап самолёт һәм артиллерия утлары астында шәһәргә азык-төлек, медикаментлар, ягулык кертелә. Ләкин аларның күпмесе генә кереп җитә алгандыр. “Тормыш юлы” буйлап картлар, балалар илебезнең төрле почмакларына, шул исәптән Татарстанга да озатыла.

## Сүзләр эзләү - Үсемлекләр


| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| э | й | ш | э | я | ц | н | к | ж | ж | ц | н | ы | б | о |
| э | б | й | ъ | д | к | ц | ч | ә | ъ | г | д | ш | й | ъ |
| и | т | ъ | э | р | з | я | а | б | ч | э | ю | ч | щ | и |
| ч | ч | м | р | б | ф | я | а | т | ц | ә | с | ш | х | х |
| щ | р | г | щ | т | з | н | б | з | ъ | ш | ч | р | я | ф |
| ы | е | ч | д | ю | ъ | т | ә | ж | р | п | р | л | м | ч |
| ц | т | ө | н | б | ө | е | к | л | а | ы | и | м | ө | ю |
| д | ә | ч | т | м | ы | ц | е | я | а | ж | м | е | э | г |
| з | ш | п | ц | й | с | з | ы | т | р | л | к | у | а | з |
| б | у | х | и | т | б | щ | х | б | э | н | н | ъ | м | ю |
| м | ә | т | р | у | ш | к | ә | й | ъ | й | и | ъ | в | а |
| е | л | л | я | и | у | э | з | ц | ъ | ы | м | ш | л | у |
| п | и | ы | б | н | н | н | л | м | й | д | с | ж | р | о |
| и | м | д | и | җ | в | ж | б | е | л | г | я | ю | и | з |
| э | щ | п | е | н | э | н | с | и | к | р | ә | н | л | л |

ТӨНБӨЕК
ТӨЛМӘЧӘК
ЯСМИН
ЛАЛӘ
УМЫРЗАЯ
ӘНҖЕ
МИЛӘУШӘ
МӘТРУШКӘ
НӘРКИС









### Табышмаклар

- ✓ Үлчәүләрдә үлчәнми,
  Базарларда сатылмый.
  (Акыл)
- ✓ Акыллы чәчә барыр,
  Акылсыз җыя барыр.
  (Белем)
- ✓ Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,
  Усалдан усалрак, дөрестән дөресрәк
  Нәрсә бар дөньяда?
  (Тел)
- ✓ Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың.
  (Мәктәп)
- ✓ Теле юк – үзе аңлата.
  (Китап)
- ✓ Җаны юк, үзе кырык төрле тел белә.
  (Каләм)
- ✓ Бер чыгарып җибәрсәң,
  Нихәтле чакырсаң да кире кайтмый.
  (Сүз)

### Мәзәкләр

❖ Укытучы:
– Вәли, дөресен әйтә әле. Кем булышты өй эшен эшләргә?
Вәли:
– Белмим, мин йоклаган идем.

❖ Гитрометүзәк вәгъдә иткән быелгы гадәттән тыш карлы һәм салкын кыш ике көн дәвам итте.

❖ – Тәмле төшләр күреп йокла, балам!
– Ә тәмле төшләр күрер өчен мендәр астына бер уч конфет куеп ятарга кирәк.

❖ Әби оныгы белән мәктәп-мәктәп уйнадылар. Соңыннан гына әби оныгы урынына дәрес әзерләгәнен абайлап алды.

❖ Химия дәресе:
– Вәли, тоз молекулалары турында хет бер әйбер әйтә алсаң, “5” куям.
– Тоз молекулалары кыяр молекулалары белән бик килешә.

**Сәхифәне әзерләделәр:** рус теле һәм әдәбияты укытучысы Газизова М.М., химия, биология һәм география укытучысы Гарифуллина Г.Д.
**Корректорлар:** туган тел һәм әдәбияты укытучылары Садриева Н.З., Юнысова Р.К.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт

**Социаль челтәр бите:** https://vk.com/77arsk_srkorsa

**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru